ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Олы Кайбыч ав. № 282

Җәйге чорда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору турында» 2020 елның 13 апрелендәге 197 номерлы карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Җәйге чорда балаларның аз йөрүен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә ремонт эшләрен башкару зарурлыгы һәм бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәйге чорда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору турында» 2020 елның 13 апрелендәге 197 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә: 1 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык «Гөлбакча» балалар бакчасы» МБМББУ;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле «Ромашка» балалар бакчасы» МБМББУ»;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит «Гөлбакча» балалар бакчасы» МБМББУ»;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чәчкаб балалар бакчасы» МБМББУ»»;

2 пунктның 8,9,12 абзацларын, 3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров